*Наконец, она вздохнула и открыла **синие, как фиалки**, **глаза** [Национальный корпус русского языка] (Finally, she sighed and opened her **violet-blue eyes** [Russian National Corpus]);*

*И синие, **синие, как воды родной реки**, **глаза** девушки туманятся теперь слезами [Национальный корпус русского языка] (The girl's eyes, which used to be blue, as blue as the waters of the native river, are now full of tears [Russian National Corpus]);*

*На щеках румянец, что маков цвет. **Глаза** игривые, **синие, как тропическое море** [Национальный корпус русского языка] (Her cheeks blush like poppies. The **eyes** are playful and as **blue as a tropical sea** [Russian National Corpus]).*

In Russian, in addition to the images mentioned above, there are often deadly images that are frequently used to describe lips and emphasize a person's inner emotions.

*За окном еще темно, а внутри вагона от тусклых лампочек у всех **лица синие, как у утопленников** [Национальный корпус русского языка] (It is still dark outside the window, and inside the carriage, because of the dim lights, everyone's faces are **blue**, **like those of drowned men** [Russian National Corpus]);*

*Однажды я подплыл к нему, с тревогой взглянул в белое, покачивающееся на воде лицо: шевельнулись **синие, как у мертвеца**, **губы** [Национальный корпус русского языка] (Once I swam up to him, looked anxiously at the white face swaying in the water: **lips**, **blue, like those of a dead man**, moved [Russian National Corpus]).*

## Conclusion

Our analysis of stable comparisons with a color component, which are often used in the Tatar and Russian languages, has led to the following conclusions.

The study shows that these comparisons, used as a means of describing and assessing the appearance and internal state of a person, are frequently found in the Tatar and Russian languages. Their active use in speech and their variety can be explained by the fact that in the environment of a person there are many objects of various colour.

In both languages, the most common colours used in comparisons are white and black. The white color reflects not only a person's appearance (hair, face, skin colour), but also the state of his/her mind (fear, anxiety, illness, etc.). In the Tatar language, this color is often used to describe purity.

Black is used to depict the color of hair, eyes, eyebrows and eyelashes. Since people with black eyes and black hair are often found among the Tatars, more comparisons with black are found in the Tatar language.

Blue and green are more common when depicting the color of eyes, less often they are used to describe lips, hands and feet, in order to show the inner experiences of a person.

The red component comparisons are used to describe the color, fullness and beauty of lips. In Russian comparisons, this color is found more often, since it is synonymous with "red" in the meaning "beautiful". The use of this color to describe noses, eyes, arms and legs emphasizes the negative attitude of the writer, or speaker.

Thus, when analyzing comparisons, firstly, the information about the object of comparison is given; secondly, the object or concept that is the standard for comparison is described. The feature, taken as the basis, is clearly expressed in the object of the comparison, therefore this sign is one of its characteristic features. The use of such comparisons in text or speech, on the one hand, names the color of the described object; on the other hand, this comparison is a signal of a positive / negative physical or psychological state of a person. The color of the ethyalon not only reveals the appearance, the color, describing a person, but also provides additional information.

Stable comparisons are a reliable object for studying the world linguistic image and a productive source for linguocultural studies, which reflect the worldview of the population, for in order to portray unfamiliar things, people almost always put it next to a similar object. Sometimes internal similarity also becomes the basis for comparison, that is, according to external features, two completely different objects or concepts coincide. It should be noted that almost always when comparing, a subjective assessment is given, a certain attitude is reflected, fixed in a language unit and an object comparable to it.

In many ways, a comparison creates a certain type of a person's image and situations.

Comparisons in the Tatar and Russian languages are characterized by similarities in the

lexical-thematic groups of images used to describe the external appearance of a person, which is explained by the universality of human nature and human thinking and, in turn, means that the understanding of the surrounding reality is described by monochromatic comparisons. The presence of specific national standards in comparisons of the two languages is associated with mythology, culture, history, literature of each nation, as well as with the individual vision of a person representing a certain nationality.

**References**


Gumbol'dt, W. (1985). *Iazyk i filosofiia kul'tury* [Language and Philosophy of Culture]. 450 p. Moscow, Progress. (In Russian)

Maslova, V. A. (2007). *Homolingualis v kul'ture: Monografiia* [Homolingualis in Culture: A Monograph]. 320 p. Moscow, Gnozis. (In Russian)

*Natsional'nyi korpus russkogo iazyka* [Russian National Corpus]. URL: https://ruscorpora.ru/new (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

Potebnia, A. A. (1993). *Mysl' i iazyk* [Thought and Language]. 302 p. Kiev, SINTO. (In Russian)

Ramazanova, D. B. (2013). *Leksika na tatarskom iazyke, otnosiashchaiasia k cheloveku* [Tatar Vocabulary Related to a Person]. P. 364. Kazan', izdatel'stvo IYALI. (In Russian)

*Tatar teleneņ yazma korpusy* [Corpus of Written Tatar]. URL: https://www.corpus.tatar (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

*Tolkovyi slovar' tatarskogo iazyka* [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. URL: http://suzlek.antat.ru (accessed: 26.08.2021). (In Tatar)

*Tolkovyi slovar' tatarskogo iazyka* (2005) [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. P. 848. Kazan', Dom pechati. (In Russian)

*Tolkovyi slovar' Ozhegova* [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. URL: https://dic.academic.ru/contents.nsf/ogegova/ (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

Zamaletdinov, R. R. (2004). *Tatarskaia kul'tura v iazykovom otrazhenii* [Tatar Culture in Linguistic Reflection]. Moscow, Gumanit. izdat. tsentr VLADOS; 239 p. Kazan', Magarif. (In Russian)


---

# КЕШЕНЕ БӘЯЛӘҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК “ТӨС” КОМПОНЕНТЛЫ ЧАГЫШТЫРУЛАР (ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕ МАТЕРИАЛЫНДА)


**Рәмзия Марс кызы Болгарова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
ramzija5@yandex.ru.

**Раушания Сәгъдәтҗан кызы Нурмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
rsagadat@yandex.ru.



Мәкаләдә татар һәм рус телләрендәге төс компонентлы компаратив конструкцияләр чагыштырма аспектта тикшерелә.

Әлеге тикшеренүнең максаты – төс атамасы кергән чагыштыруларны кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау һәм бәяләү чарасы буларак өйрәнү. Татар теленең язма корпусыннан, рус теленең милли корпусыннан алынган мисаллар тикшеренү материаллары буларак файдаланылды. Төс компонентлы чагыштырулар кешеләрнең тышкы кыяфәтендәге табигый үзенчәлекләрне яки кешенең физик яки психологик халәтендәге тышкы билгеләрне тасвирлаганда кулланыла. Әлеге образлы сурәтләү чаралары чагыштырылучы предметның һәм образның нинди булуына карап, уңай яки тискәре образ тудырырга мөмкин.

Фәнни-тикшеренү эшенең нәзари һәм гамәли әһәмияте хезмәтнең төп нәтиҗәләрен татар һәм рус телләре лексикологиясе, лингвомәдәниятне өйрәнүгә юнәлдерелгән хезмәтләрдә файдалану мөмкинлеге белән билгеләнә.



**Төп төшенчәләр:** татар теле, рус теле, чагыштырулар, төс компоненты, кешенең тышкы кыяфәте.


## Кереш

Кешенең әйләнә-тирә дөнья турындагы барлык күзаллаулары аның аңында формалаша һәм алар күп очракта фикерләүнең ассоциатив характеры белән аңлатыла. Кеше образы – гомумтел дөнья сурәтендә дә, милли дөнья

сурәтендә дә төп образларның берсе. Шуңа күрә кешене сурәтләгән тотрыклы компаратив тел берәмлекләрен тикшерү аның телдә чагылыш тапкан образын тулысынча күз алдына китерергә ярдәм итә.

Әйтергә кирәк, кеше образы – милли дөньяны кабул итүнең бер чагылышы. Төрле мәдәният вәкилләре үз күзаллауларына ия, дөнья турындагы мәгълүматны үзләренчә кабул итә. В. Гумбольдт фикеренчә, "төрле телләр – бер үк әйбернең төрле исемнәре генә түгел, ә аларга төрлечә караш та ул" [Гумбольдт, 1985, б.154]. Шуңа күрә дөнья сурәте телдә бары тик милли-мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып кына тасвирланырга мөмкин.

А.А. Потебня билгеләп үткәнчә, "сүз ярдәмендә кеше үзенең аңында булган нәрсәләрне яңадан танып белә. Ул бер үк вакытта хаостан яңа дөнья да иҗат итә һәм бу дөньяның чикләрен киңәйтү өчен үзенең көчен арттыра" [Потебня, 1993, б. 302].

Тотрыклы чагыштырулар – татар һәм рус телләрендә актив кулланыла торган берәмлекләр. Алар образлы, тәэсирле сөйләм чаралары, күпчелек очракта сөйләүченең яки язучының хис-кичерешләрен үз эченә ала. Фразеологиянең төрле катламнарындагы кебек үк, чагыштыруларда да халыкның күпгасырлык тәҗрибәсе тупланган. Шулай ук чагыштырулар мәдәни ассоциацияләр, тел һәм мәдәни тәҗрибә белән дә бәйле була.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Татар теленең язма корпусыннан, рус теленең милли корпусыннан алынган мисаллар фәнни-тикшеренү эшенең материалы булып хезмәт итте.

Әлеге корпуслардан кешене тасвирлый торган төс компонентлы чагыштырулар кергән мисаллар тупланды, ике телдә дә иң еш кулланылучы *кебек, как*, шулай ук төс белән турыдан-туры бәйле *төсле* бәйләүче чаралары ярдәмендә төзелгән чагыштырулар тикшерелде.

Мәкаләдә фактик материалны анализлаганда, күзәтү, чагыштырма, тасвирлама һәм семантик анализ методлары кулланылды.

## Фикер алышу

Кешенең тышкы кыяфәте буенча билгеле бер күләмдә мәгълүмат алырга, аның милләтен, җенесен, яшен, шулай ук шәхси үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкин. Гомумән, кешенең тышкы кыяфәте, аларны сурәтләү үзенчәлекләре милли мәдәният турында да күп нәрсә сөйли. Гадәттә, кешене тасвирлаган вакытта һәрвакытта да уңай һәм тискәре бәяләмәләр кулланыла. Әлеге хезмәттә татар һәм рус телләрендәге "төс" компонентлы чагыштырулар кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау һәм бәяләү чарасы буларак анализланды.

Төсләр, кешенең тышкы кыяфәте һәм эчке дөньясы үзенчәлекләренә өстәмә характеристика бирү максатында, билгеле бер объект яки күренеш белән чагыштыруның нигезен тәшкил итә. Төрле мәдәният вәкилләре бер үк төсне, аларның әһәмиятенә карап, төрлечә кабул итә һәм бәяли.

Төсләр символикасы белән кеше аңы катламнары, халыкның тарихы, мәдәни-иҗтимагый тормышы арасында тирән бәйләнеш бар. Төсләр төрле мәгънәләр белдерергә, төрле хисләр уятырга һәм ассоциацияләр тудырырга сәләтле, шул рәвешле алар кешенең психик дөньясында аерым һәм үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка китерә. Төсләргә нисбәтле ассоциацияләр дөньяны шәхси, милли, дини һ.б. кабул итү үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Кешеләр элек-электән төсләргә аерым игътибар биргәннәр, болар халыкның ышануларында, борынгы риваятьләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә, дини тәгълиматларда урын алган.

Төсләр семантикасының үзенчәлеге – күпмәгънәлелектә. Һәр төстә бик күп төрле мәгънәләр яшеренгән. Тотрыклы лексик берәмлекләрдә төс атамаларының нәкъ менә шул сыйфаты калкып чыга.

Фәнни тикшеренүдә татар һәм рус телләрендә тәңгәллекләре булган һәм еш кулланылган төс атамалары (татар телендә: *ак, кара, кызыл, яшел, зәңгәр*; рус телендә: *белый, черный, красный, зеленый, синий*) кергән чагыштыруларга төп игътибар бирелде.

Кешелек мәдәниятендә *ак* һәм *кара* иң борынгы төсләрдән санала. Татар һәм рус телләрендәге чагыштыруларда бу төс атамалары бик еш очрый, моны әлеге төсләрнең танып-белүдәге һәм мәдәни әһәмиятенә бәйләп аңлатырга мөмкин.

Ак төс.

АК I с. 1. 1) Кар, сөт төсендәге; киресе: кара.

2) Үз төсен югалткан, чал, чаларган, көмеш төсле.

3) Ялтырап торган көмешсыман төстәге, өстеннән никель йөгерткән.

4) Борчылудан, каушаудан, авырудан йөзе үзгәргән, төсе, чырае киткән, агарынган.

5) махс. Ике яки өч сүздән торган зоологик һәм биологик терминнарның (атамаларның) беренче кисәге.

6) күч. Чиста, керсез, пычранмаган, юылган (кием-салым турында).

7) күч. тар. Революциягә һәм Совет хөкүмәтенә каршы булган.

8) күч. Алдынгы; укымышлы, прогрессив.

9) күч. Язмыйча, буш калдырып, фикернең тәмамланмавына, яшерен эчке мәгънә булуына ишарә иткән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

Б , -ая, -ое; бел, бела, бело и бело.

1. Цвета снега или мела.

2. полн. Светлый, в противоположность чему-н. более тёмному, именуемому чёрным.

3. полн. В первые годы гражданской войны: относящийся к вооружённой борьбе за восстановление законной власти в России.

4. белый, -ого, муж. То же, что белогвардеец.

5. полн. Со светлой кожей (как признак расы). Цветные и белые (сущ.) [Толковый словарь Ожегова].

Татар телендә “ак” компоненты кергән чагыштырулар кешенең тәнен, йөзен, тешләрен, кулларын, чәчләрен, сакал-мыекларын һ.б. тасвирлаганда актив кулланыла. Чагыштыру объекты буларак еш кына *кар, сөт, шикәр, мамык, аккош, шалкан, киндер* сүзләре килә. Мәсәлән:

*– Иптәшләр, ишкәкләргә ныграк басыгыз! – дип пышылдый Искәндәр, һәм караңгыда аның* ***кар кебек ак тешләре*** *ялтырап китәләр* [Татар теленең язма корпусы];

*Йөзләренә таңның алсу төсе кунган,* ***шикәр кебек ак йөзле*** *Любаша аерылышуны үзенчә кичерде* [Татар теленең язма корпусы];

*Хәзрәт* ***мамык кебек ак****, йомшак* ***кулларын*** *биреп саубуллашты да җир өстендә йөзгән томан кебек, салмак кына атлап китеп барды* [Татар теленең язма корпусы];

*Көзгегә караганчы ук мин кулларымның* ***сабыйларныкы кебек ак*** *һәм җыерчыксыз булуын күрәм* [Татар теленең язма корпусы];

*Вәгъдәгөл карчыкны күргәч, Вера гаҗәпләнеп куйды:* ***башы кар кебек ак****, ник ичмасам бер кара чәче күренсен* [Татар теленең язма корпусы];

*Хәтта шәһәребезнең атаклы галиме, тарих фәннәре докторы Вәли ага үзе дә, куллары белән* ***кар кебек ак чигәләрен*** *кысып, бүлмәдә әрле-бирле йөренә һәм сөйләнә иде...* [Татар теленең язма корпусы];

*Картның* ***сөт кебек ак сакалы*** *калтыранып китте* [Татар теленең язма корпусы];

*Юк, ятим булмас анның әтисе кебек үк киң маңгайлы, зур кара күзле,* ***кызлар кебек ак йөзле****, озын керфекле улы* [Татар теленең язма корпусы];

***Тәне шалкан кебек ак*** *һәм тыгыз, җилкәләре киң иде Гафурның* [Татар теленең язма корпусы].

Югарыдагы мисалларда *кар, сөт, шикәр, мамык, сабый* һ.б. образлар уңай тәэсир тудыра.Әлеге эталоннар сүзлектә бирелгән аңлатмалар белән дә туры килә.

*Менә мин нишлим, менә ник* ***битем киндер кебек ак****, менә ник минем күзләрем тиле кешенеке кебек!* [Татар теленең язма корпусы];

*Нәрсә булды,* ***йөзең чүпрәк кебек ак****? – диде аңа тегесе* [Татар теленең язма корпусы].

Әлеге чагыштыруларда да ак төс кулланыла, тик *киндер, чүпрәк* образлары аша кешенең кыяфәтенә тискәре бәя бирелә.

Ак төснең кеше аңына эмоциональ тәэсире көчле, чөнки ул яктылык, көн, чисталык белән бәйле ассоциацияләр тудыра. Болар барысы да ак төснең уңай бәя бирүдә катнашуына нигез булып тора. Шуңа күрә “ак” компонентлы чагыштырулар ярдәмендә кеше күңеленең чисталыгы, сафлыгы да сурәтләнә. Бу чагыштырулар да кешегә уңай бәя бирү өчен кулланыла. Мәсәлән:

*Шул мизгелдә сине җиргә төшереп, теге* ***Хозыр Ильяс кебек ак Бабай****, елмаймыйнитми, китаплар артыннан килеп чыга һәм синең кулыңа озынлыгы ике метрдан да ким булмаган очлы таяк тоттыра* [Татар теленең язма корпусы];

*Зөбәйдә –* ***кар кебек ак****, су кебек пакь* ***кыз*** [Татар теленең язма корпусы];

***Ул*** *да бүген нәкъ шул* ***каен кебек ак*** *иде, биек иде һәм бәхетле иде, кичәге көнне кичәгесендә калдырып, бүген чиксез бәхетле иде* [Татар теленең язма корпусы].

Татар телендә *ак* сүзе, *көл, май* лексемалары белән бер сүзтезмәдә килеп, үзенчәлекле образ тудыруда катнаша. Мәсәлән:

*Кадермәтнең* ***йөзе көл кебек ак****, иреннәре күгәреп каткан...* [Татар теленең язма корпусы];

***Йомарлак май кебек ак тезләр****ен каплар-капламас чуар күлмәк...* [Татар теленең язма корпусы].

Бу чагыштырулар, контекстка карап, кешегә уңай бәя дә, тискәре бәя дә бирергә мөмкин.

Рус телендә “ак” компонентлы чагыштырулар да тән, йөз, чәч, сакал һ.б.ны сурәтләгәндә еш кулланыла. Рус теленең аңлатмалы сүзлегендә дә ак төс кар, акбур төсе белән чагыштырып аңлатыла. Шуңа күрә чагыштыру объекты буларак, шулай ук *кар, акбур, кәгазь, мамык, сөт, он, каен* һ.б. образлары киң таралыш алган. Мәсәлән:

*Его атласные* ***волосы, белые, как снег,*** *были расчесаны; он разглаживал седую бороду* [Национальный корпус русского языка];

*Подошёл* ***Василий*** *совсем близко: лица на нём нету,* ***белый, как мел****, глаза дикие; говорить начал – голос обрывается* [Национальный корпус русского языка];

*Нюрка стала реветь без слов, а* ***Володя, белый как бумага****, лепетал и точно боролся с кем-то, кто подшибал его под коленки, опрокидывал навзничь и душил* [Национальный корпус русского языка];

*Оксана обернулась – брат был* ***с лица белый как простыня*** *и белой же рукой указывал на что-то там, на земле* [Национальный корпус русского языка];

*Номер вполне мог стать смертельным, и* ***Виталий*** *действительно на миг потерял сознание, но все же опомнился и,* ***белый, как полотно****, самоотверженно довел до конца эпизод с канарейкой* [Национальный корпус русского языка];

*Бросила взгляд на Рапопорта –* ***он белый как скатерть*** [Национальный корпус русского языка].

Рус телендә *лунь, покойник, смерть* һ.б. сүзләре белән бер сүзтезмәдә кулланылып, үзенчәлекле образлар тудыру да еш очрый. Мәсәлән:

*Седые* ***волосы, белые как лунь****, бритое лицо – некрасивое, но интересное каждою морщинкой* [Национальный корпус русского языка];

***Фомич*** *сидел посреди дороги,* ***белый как покойник****, и еле дышал, убитый жарой* [Национальный корпус русского языка];

*Хмель из плотника вышибло, а рядом,* ***белый, как смерть****, стоял* ***шофер*** [Национальный корпус русского языка].

Кеше йөзенең аксыллыгы рус телендә үлем белән тиңләштерелә, *смерть, покойник* образлары аша кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, физик халәте дә, эчке кичерешләре дә тасвирлана.

Мисалларда ике телдә кулланылган образларның лексик-тематик төркемнәре охшаш булуы ачык күренә. Татар һәм рус телләрендә “ак” компонентлы чагыштырулар кешенең чәчләрен (чал чәчләрне), тешләрен, тән төсен, шулай ук физик һәм эмоциональ халәтен (авыру, ару, борчылу, курку һ.б.) сурәтләү өчен кулланыла.

Кара төс.

КАРА I с. 1. 1) Корым төсендәге; иң караңгы төсле.

2) Куерак, караңгырак төстәге.

3) Караңгы; яктылык төшми торган, куе, калын.

4) Негроид расаның билгесе буларак, ак тәнлеләрдән нык аерылган караңгы төстәге.

5) Тумыштан каратутлы, чәче һәм тән төсе башкаларныкыннан караңгырак булган.

6) Кояш астында озак булудан, җылы якларда яшәүдән аклыгын югалткан, каралган, кояшта кызган (кешедә бит, тән төсе тур.).

7) Керле, пычрак, юынмаган.

8) Сөт кушылмаган (чәй, кофе һ.б.ш.).

9) иск. Махсус исерткеч итеп эшләнә торган (кымыз).

10) Морҗасыз, төтене махсус тишектән – төнлектән чыга торган (мунча, өй тур.).

11) иск. Хезмәтчеләр тора торган, кышын терлек-туар кертелә торган (өй, бүлмә тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

ЧЁРН , -ая, -ое; чёрен, черна, черно и чёрно.

1. Цвета сажи, угля.

2. полн. Тёмный, в противоп. чему-н. более светлому, именуемому белым.

3. Принявший тёмную окраску, потемневший.

4. полн. В старину: то же, что курной. Чёрная баня.

5. перен. Мрачный, безотрадный, тяжёлый.

6. полн., перен. Преступный, злостный.

7. полн. Не главный, задний (о входе, ходе).

8. полн. О труде: физически тяжёлый и неквалифицированный.

9. полн. Принадлежащий к непривилегированным, эксплуатируемым классам общества (устар.).

10. полн. На Руси в 1217 вв.: государственный, не частновладельческий.

11. полн. С тёмной кожей (как признак расы), чернокожий [Толковый словарь Ожегова].

Элек-электән кешеләр кара төсне төн, караңгылык белән бәйләгәннәр. Бу төс кеше аңында куркыныч ассоциацияләр барлыкка китергән. Шунлыктан әлеге төс кергән чагыштырулар ике телдә дә тискәре образ тудыра. Мәсәлән:

***Чырайлары корым сарган кебек кара*** *көйгән* [Татар теленең язма корпусы];

*Берни дә барып чыкмагач,* ***шайтан кебек кара йөзле****, сасы сарымсак белән тәмәке исе аңкытып торган урыс аны этә-төртә урамга куып чыгарды* [Татар теленең язма корпусы];

*Аннан таза гәүдәле,* ***сумала кебек кара чырайлы****, кысык күзле, чәче-кашы ат кылын хәтерләткән адәм күренде* [Татар теленең язма корпусы];

*Чырайлары чытык,* ***битләре кайрак кебек кара*** *янган* [Татар теленең язма корпусы];

*Совсем как этот: усатый,* ***черный, как головешка****, со злым лицом* [Национальный корпус русского языка];

*Иногда приходил* ***черный как туча****, вздрагивал от каждого шороха* [Национальный корпус русского языка];

*В центре группы на охапке сена возлежал* ***черный, как негр, детина*** *с одной ногой* [Национальный корпус русского языка];

***Арап*** *лежал в гробу в морском мундире времени Екатерины,* ***черный как уголь...*** [Национальный корпус русского языка];

Әлеге төс кергән чагыштыруларны ике телдә дә чәч, күз, каш, керфекләрне тасвирлаганда да күзәтергә мөмкин. Эталон буларак, *төн, сумала, күмер, җир, болыт, шомырт, карлыган, карга, карга канаты, гарәп, чегән* һ.б. сүзләр актив кулланыла. Мәсәлән:

***Күзләре*** *минекенә охшаган,* ***төн кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы];

*Чигә* ***чәчең*** *кара иде, /* ***Сумала кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы];

*Алланып торган кояш чыгышыннан китерелгән җитез егетнең* ***шомырт кебек кара күзләренә*** *кылдан нечкә итеп очланган инәләр кададылар, ди* [Татар теленең язма корпусы];

*Ул арада сигез-ун яшьлек яланаяк, яланбаш, үзләре* ***ком гарәбе кебек кара янган*** *ике* ***малай*** *килеп чыкты* [Татар теленең язма корпусы];

***Чегән кебек кара чәчле****, кара тәнле булганы өчен генә түгел, ә эшчеләр арасында иң яше булганга да, аңа шулай дип дәшәләр иде* [Татар теленең язма корпусы];

*Телефон баганасыдай озын,* ***мунча ташы кебек кара Хәниф*** *иде ул* [Татар теленең язма корпусы];

*Икенчесе егерме-егерме биш яшьләрдәге егет, ә яңакларында* ***кара урман кебек кара сакал*** [Татар теленең язма корпусы];

***Төн кебек кара****, ишелеп төшкән* ***чәчләрен*** *төзәтеп куйды* [Татар теленең язма корпусы];

***Күмер кебек кара чәчләре*** *арасында көмешсу көл сибелгән кебек* [Татар теленең язма корпусы];

*Аннан калын гына гәүдәле, тулы битле, кысыграк күзле бер кеше төште,* ***кашы, чәчләре сумала кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы].

Рус телендә дә шул ук образлар еш очрый. Мәсәлән:

*Лица их были смуглые, носы приплюснутые и губы толстые,* ***глаза чёрные, как смоль****, равно как и волосы, висящие прядями, иные были с редкими бородами, иные же и вовсе без бород; в разные части лица были у них воткнуты длинные косточки и вставлены камешки* [Национальный корпус русского языка];

*И я, подчиняясь моему порыву, наклонилась к ней и нежно поцеловала ее* ***глаза, черные, как ночь****, и горящие, как алмазы* [Национальный корпус русского языка];

*Передок занимал квадратный,* ***черный как ворон мужик****...* [Национальный корпус русского языка];

*Лицо у него было смуглое, два черных глаза горели, как угли, не покрытые париком короткие* ***волосы, черные, как воронье крыло****, вились мелкими кольцами, и весь он был одет в черное* [Национальный корпус русского языка];

***Лёва*** *высокий, стройный,* ***чёрный, как цыган****, Олеся ему по плечо, белолицая русалочка с льняными волосами...* [Национальный корпус русского языка].

Әлеге төс ярдәмендә, чагыштырыла торган предметның һәм образның нинди булуына карап, уңай яки тискәре образ күзалланырга мөмкин.

Кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлаганда (чәч, күзләр, каш, керфек), кара төс еш кына уңай тәэсир калдырса, кешенең физик халәтен яки эчке кичерешләрен сурәтләгәндә тискәре образ тудыра.

Кызыл төс.

К З I с. 1. 1) Спектрның төп төсләреннән иң беренчесе төсле, кан төсендәге.

2) сөйл. оны, төкләре кызгылт көрән, куе җирән төсле (сыер, бозау төсе тур.).

3) Кызыл төс алган, беркадәр кан төсе кергән, кызарган.

4) тар. Октябрь революциясенә, революциядә катнашучыларга, большевикларга, революцион эшчәнлеккә бәйләнешле; Советлар Союзына, Кызыл Армиягә караган.

5) иск. тар. Җәдитчеләр хәрәкәтендә катнашучы, җәдитчелек тарафында булган.

6) күч. Һич тайпылмыйча билгеле бер карашны яклаучы, эзлекле тарафдар булган, ортодокс булган.

7) Ботаника, зоология, минералогия кебек фәннәрдәге кайбер тезмә терминнарның беренче компоненты буларак кулланыла.

8) Югары пробалы, саф (кыйммәтле металлар тур.).

9) Югары уку йортын «бик яхшы» билгеләре белән генә тәмамлаган студентларга бирелә торган (диплом тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

КРАСН , -ая, -ое; -сен, -сна, -сно и -сно.

1. (-сно). Цвета крови, спелых ягод земляники, яркого цветка мака.

2. полн. Относящийся к революционной деятельности, к советскому строю, к Красной Армии.

3. Употр. в народной речи и поэзии для обозначения чего-н. хорошего, яркого, светлого.

4. полн. Употр. для обозначения наиболее ценных пород, сортов чего-н. (спец.).

5. красный, -ого, муж. Сторонник или представитель большевиков, их революционной диктатуры, военнослужащий Красной Армии [Толковый словарь Ожегова].

Кызыл төс башка төсләр арасында үзенең яктылыгы һәм матурлыгы белән аерылып тора, әлеге төснең күчерелмә мәгънәләре дә күп. Күп кенә халыкларда ул изге төс булып та санала, еш кына кан, ут төсе белән бәйләп карала.

“Кызыл” компонентлы чагыштыруларда күп очракта эталон буларак, бакча һәм кыр чәчәкләре исемнәре (мәк чәчәге, чәчәк, гөлчәчәк һ.б.), җиләкләр, җиләк-җимеш, яшелчә исемнәре файдаланыла. Мәсәлән:

*Оятыннан **гөл кебек кызыл йөзе**, Ак киемнән, алтын таҗ кигән үзе* [Татар теленең язма корпусы];

*Кырысрак сыман күренгән хатын бала янында бөтенләй эреде, ул аны иркәли, **алма кебек кызыл битләреннән** үбә башлады* [Татар теленең язма корпусы];

*Ә анда, авызын ерып, **җиләк кебек кызыл чырайлы** Әнвәр абый бүрәнә юнып маташа иде* [Татар теленең язма корпусы];

*Кызый чибәр, аның карлыгандай кара күзләренә, **чия төсле кызыл иреннәренә**, алма кебек тыгыз, түгәрәк күкрәкләренә сокланып карап тормыйча түзеп булмый* [Татар теленең язма корпусы];

***Йөзе чөгендер кебек кызыл** иде* [Татар теленең язма корпусы].

Рус телендә әлеге төркемгә караган чагыштыруларда чәчәк, җиләк-җимеш, яшелчә исемнәреннән тыш, хайван исемнәре, ут-ялкын образлары да еш очрый, бу төснең метафорик мәгънәләре дә күбрәк. Мәсәлән:

***Красный, как пион**, **Соткин** смотрел в холодное лицо унтера едва не умоляющими глазами* [Национальный корпус русского языка];

*Быстро исчезнет с него тогда человеческий облик: обрюзглая, посиневшая физиономия, **губы красные, как огонь**, и мутные глаза выразят в телесных формах неутолимую тоску его души* [Национальный корпус русского языка];

*Какой **он** сидел тогда **красный, как помидор** спелый, как из города Омского явился, думал я, ему веку не будет…* [Национальный корпус русского языка];

***Он** смутился и стал **красный, как свекла*** [Национальный корпус русского языка];

*Несколько справившись с собою, весь **красный как рак, он** объявил, что счёл долгом поднять рубашечку, лично принести её...* [Национальный корпус русского языка];

*Подкосились снова ноженьки у Наташи, а **Василий** уже идет к ней, идет – весь **красный, как огонь**, от крови, глаза горят у него, как костры в темной ночи, – и он к ней руки тянет* [Национальный корпус русского языка];

*А только что **он** был **красный, как пожар*** [Национальный корпус русского языка].

Әлеге төркемдәге чагыштырулар кешенең иреннәрен тасвирлаганда уңай образ тудыра, физик яки рухи халәтен чагылдырганда, кешенең күзләрен, борынын, бит төсен сурәтләгән вакытта, киресенчә, язучының яки сөйләүченең тискәре карашын күрсәтә.

Яшел төс.

ЯШ сф.

1. Спектрда төп төсләрнең берсе – зәңгәр белән сары арасындагы төс; үлән, үсемлек, яфрак төсе.

2. Үлән үскән, яшеллек каплаган [яшел болын].

3. Үләннән, яфрактан торган [яшел азык]. Ашарга яраклы үләннәрнең (кузгалак, кычыткан һ.б.ш.) яфрагыннан әзерләнгән. яңа чабылган, яңа өзелгән [яшел печән].

4. Җиләк-җимеш, ашлык һ.б.ш. тур.: өлгермәгән, җитлекмәгән. рәв. Өлгермәгән килеш [арыш яшелрәк урылган].

5. күч. Бик яшь һәм тәҗрибәсез [бераз яшьрәк һәм яшелрәк булса да] [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 738].

З ЁН , -ая, -ое; зелен, зелена, зелено, зелены и зелены.

1. Цвета травы, листвы.

2. О цвете лица: бледный, землистого оттенка (разг.).

3. полн. Относящийся к растительности; состоящий, сделанный из зелени (во 2 и 3 знач.).

4. О плодах: недозрелый [Толковый словарь Ожегова].

"Яшел" компонентлы чагыштырулар татар һәм рус телләрендә күп түгел. Ике телдә дә, гадәттә, кешенең күзләрен тасвирлаганда кулланыла, образ буларак үсемлекләр, кыйммәтле ташлар (зөбәрҗәт, малахит), хайван исемнәре һ.б. белән янәшә килә. Мәсәлән:

*Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Поцелуйкин, кулларын угалап, утырган урынында сикереп куйды, **мәченеке кебек яшел күзләре** кечерәеп, җыерчыклар эчендә тәмам югалып калды, томшык борыны тагын да нечкәреп киткәндәй булды* [Татар теленең язма корпусы];

*Рәбиганың яшел болыннардагы **күлләрнең суы төсле яшел күзләре** минем каршымда ич...*[Татар теленең язма корпусы];

*Менә ни төсле икән аның күзләре! **Малахит ташы төсле яшел*** [Татар теленең язма корпусы];

*Ул сарыктан кеше ясаудан ләззәт таба, ә син аның белән янәшә булудан, аның **җәй төсле яшел күзләренә** рәхәтлек кичерәсең* [Татар теленең язма корпусы];

*У них были совершенно одинаковые глаза — **зеленые, как крыжовины**, в светлых ресницах* [Национальный корпус русского языка];

*Увидел, что она мулатка, что плечи у нее мягкие и округлые, а **глаза зеленые, как у кошки*** [Национальный корпус русского языка];

*Лысый безрукий верзила. **Глаза зеленые, как трава*** [Национальный корпус русского языка];

*– Только нос немножко широк да **глаза зеленые, как у ящерицы*** [Национальный корпус русского языка].

Чагыштыруларның күбесендә яшел күзләр уңай тәэсир калдыра, образларында тискәре коннотация булганнары, киресенчә, кешенең кыяфәтен дә, эчке дөньясын да ямьсез итеп күрсәтә.

Зәңгәр төс.

ЗӘҢГӘР с. 1. 1) Спектрда яшел белән күк арасындагы төп төсләрнең берсе – күк йөзенең аяз көндәге ачык төсе, диңгез төсе.

2) күч. Ачы, югары тондагы; көчле, чәрелдәп торган.

2. и. мәгъ. 1) Зәңгәр төс, зәңгәр буяу [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

СИНИ , -яя, -ее; синь, синя, сине.

1. Имеющий окраску одного из основных цветов спектра среднего между фиолетовым и зелёным.

2. О коже: сильно побледневший, приобретший оттенок этого цвета [Толковый словарь Ожегова].

Татар һәм рус теле чагыштыруларында зәңгәр төснең төп функциясе – күзләрнең төсенә характеристика бирү. Моннан тыш, чагыштыруларда кулланылган образлар күзләрнең төсен генә түгел, күп вакытта формасын да ачыклый, кешенең эчке кичерешләренә дә ишарә итә. Ике телдә дә *диңгез, күл, су, һава, күк, чәчәк, кыр чәчкәсе* һ.б. образлар еш очрый. Мәсәлән:

***Су кебек зәңгәр күзле**, җирән чәчле, ди, үзләре* [Татар теленең язма корпусы];

***Төпсез күл кебек зәңгәр күзләре** сөйкемле генә карый иде* [Татар теленең язма корпусы];

***Кыр чәчкәсе кебек зәңгәр күзле** кыз!* [Татар теленең язма корпусы];

***Кыр чәчәге төсле зәңгәр күзләрендә** борчылу* [Татар теленең язма корпусы];

*Ятаклар аслы-өсле куелган бүлмәчеккә төшсәң, шул ук таныш йөзләргә, озынча, кылычтай, төерчекле борынга, нәселле этнеке төсле тырпаеп торган яисә башка ябышкан колакка, табигать биргән төсен отыры үзгәртми торган өлгергән борчактай соры, **күк йөзе төсле зәңгәр күзләргә**, хатын-кыз турында тәмсез мәзәк сөйләргә җайланган чапылдык авызларга юлыгасың* [Татар теленең язма корпусы];

*Туп-туры күзгә карап алулары, алсу битләре, матур колак яфраклары, **аяз күк кебек зәңгәр күзләре**, озын, бөгелеп торган керфекләре, аяк атлаулары...*[Татар теленең язма корпусы];

*Халкы да матур, егетләрнең күбесе озын буйлы, калын бәдәнле, кыю карашлы; кызлары елга камышыдай зифа буйлы, **төпсез диңгез кебек зәңгәр күзләр*** [Татар теленең язма корпусы];

*Чөенке борынлы, сипкелле, **күк әчү ташы кебек зәңгәр күзле**, шомырт кара чәчле кыз бу озын чәчле ирнең ушын алды, **күл өсте кебек***

***зәңгәр*** *хәзер аның* ***күзләре*** [Татар теленең язма корпусы];

*Остается летний день, шевелящий листочки, березки, белые, как облака,* ***глаза, синие, как небо*** *над облаками…*[Национальный корпус русского языка];

***Синие, как небо*** *Памира,* ***глаза*** *Люды радостно сверкали, когда вбежала она в отдел археологии, бросила на стол две золотистые монетки и торжествующе сказала...* [Национальный корпус русского языка];

***Глаза*** *у нее* ***синие, как цветочки****, и смотрела она до слез доверчиво* [Национальный корпус русского языка];

*Наконец, она вздохнула и открыла* ***синие, как фиалки****,* ***глаза*** [Национальный корпус русского языка];

*И синие,* ***синие, как воды родной реки****,* ***глаза*** *девушки туманятся теперь слезами* [Национальный корпус русского языка];

*На щеках румянец, что маков цвет.* ***Глаза*** *игривые,* ***синие, как тропическое море*** [Национальный корпус русского языка].

Рус телендә югарыда әйтелгән образлардан тыш, үлем белән бәйле образлар да бар, алар бит, иреннәрне тасвирлаганда актив һәм кешенең эчке хис-кичерешләрен дә ассызыклый.

*За окном еще темно, а внутри вагона от тусклых лампочек у всех* ***лица синие, как у утопленников*** [Национальный корпус русского языка];

*Однажды я подплыл к нему, с тревогой взглянул в белое, покачивающееся на воде лицо: шевельнулись* ***синие, как у мертвеца****,* ***губы*** [Национальный корпус русского языка].

### Нәтиҗәләр

Татар һәм рус телләрендә еш кулланыла торган төс компонентлы тотрыклы чагыштыруларны анализлау шундый нәтиҗәләргә китерде.

Татар һәм рус телләре материалында үткәрелгән тикшеренү кешенең тышкы кыяфәтен һәм эчке халәтен тасвирлау һәм бәяләү чарасы буларак, төс компонентлы чагыштыруларның күп булуын күрсәтте. Мондый чагыштыруларның төрлелеге кеше тормышындагы, әйләнә-тирәдәге төсле предмет, объектларның да гаять төрле булуы, аларның сөйләмдә актив кулланылуы белән дә бәйле.

Ике телдә дә чагыштыруларда иң еш очраган төсләр – *ак* һәм *кара*. Ак төс кешенең тышкы кыяфәтен (чәч, бит, тән төсе) генә түгел, аның күңел халәтен дә (курку, борчылу, авыру һ.б.) чагылдыра. Татар телендә әлеге төс сафлык, чисталыкны сурәтләү өчен дә еш кулланыла.

Кара сүзе ярдәмендә чәч, күз, кашкерфекләр төсе сурәтләнә. Татар халкында кара күзле, кара чәчле кешеләр еш очраганга күрә, бу төс кергән чагыштырулар да татар телендә күбрәк.

*Зәңгәр* һәм *яшел* төс ешрак күз төсенә нисбәттә, кайбер вакытта кешенең эчке кичерешләрен күрсәтү максатыннан, иреннәр, кул-аяклар һ.б. тасвирлаганда да очрый.

*Кызыл* компонентлы чагыштырулар күп вакыт иреннәрнең төсен, тулылыгын, матурлыгын күрсәтү өчен кулланыла. Рус телендәге чагыштыруларда әлеге төс ешрак очрый, чөнки красный (кызыл) красивый (матур) сүзенең синонимы буларак та йөри. Әлеге төс борын, күз, кул һәм аякларны тасвирлаганда язучының яки сөйләүченең негатив карашы ассызыклана.

Шулай итеп, чагыштыруларны анализлаган вакытта, беренчедән, чагыштыру объекты турында, икенчедән, чагыштыру өчен эталон булган предмет яки төшенчә турында мәгълүмат туплана. Чагыштыру нигезенә алынган билге чагыштыру объектында бик ачык белдерелә, шунлыктан әлеге билге аның характерлы сыйфатларыннан берсе булып тора. Текстта яки сөйләмдә мондый чагыштыруларны куллану, бер яктан, тасвирлана торган объектның төсен белдерсә, икенче яктан, әлеге чагыштыру кешенең уңай / тискәре физик яки психологик халәтенең сигналына да әйләнә. Эталонның төсе кешенең тышкы кыяфәтен, төсен генә ачыклап калмый, өстәмә мәгълүмат та бирә.

Тотрыклы чагыштырулар – дөнья тел сурәтен өйрәнү өчен ышанычлы объект һәм лингвомәдәни тикшеренүләр өчен продуктив чыганак, аларда халыкның дөньяга карашы чагылыш таба. Чөнки таныш булмаган әйберне сурәтләү өчен, кешеләр һәрвакытта да диярлек аны охшаш объект белән янәшә куялар. Кайвакыт эчке охшашлык та чагыштыру өчен нигез була, ягъни тышкы билгеләре буенча бөтенләй охшаш булмаган ике предмет яки төшенчә тәңгәлләштерелә. Тагын шуны да әйтергә кирәк, чагыштырган вакытта һәрвакыт диярлек субъектив бәя дә бирелә, тел берәмлегенә һәм аның аша чагыштырыла торган объектка карата телдә беркетелгән билгеле бер мөнәсәбәт тә чагылдырыла.

Чагыштыру күп вакытта кешеләрнең, ситуацияләрнең билгеле бер типтагы образларын тудыра.

Татар һәм рус телләрендәге чагыштыруларга кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау өчен кулланылган образларның лексик-тематик төркемнәре охшашлыгы хас булуы ачыкланды. Бу кеше табигатенең һәм кеше фикерләвенең универсальлеге белән аңлатыла һәм, үз чиратында, әйләнә-тирә чынбарлыкны аңлауның бертөрле чагыштырулар ярдәмендә тасвирлануын күрсәтә. Ике телнең чагыштыруларында милли үзенчәлекле эталоннар булу һәр милләтнең мифологиясе, мәдәнияте, тарихы, әдәбияты белән, шулай ук билгеле бер милләт кешесенең индивидуаль күзаллавы белән бәйле.

**Әдәбият**

*Гумбольдт* В. Язык и философия культуры. М.: Прогресс, 1985. 450 с.

*Замалетдинов* Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. М: Гуманит. издат. центр В АДОС; Казань: Магариф, 2004. 239 с.

*Маслова* В.А. Homolingualis в культуре: Монография. М.: Гнозис, 2007. 320 с.

Национальный корпус русского языка [Электронный ресурс]. URL: https://ruscorpora.ru/new (дата обращения: 26.08.2021).

*Потебня* А.А. Мысль и язык. Киев: СИНТО, 1993. 302 с.

*Рамазанова* Д.Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан: ИЯ И нәшр., 2013. 364 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге [Электрон ресурс]. URL: http://suzlek.antat.ru (мөрәҗәгать итү вакыты: 26.08.2021).

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең язма корпусы [Электрон ресурс]. URL: https://www.corpus.tatar (мөрәҗәгать итү вакыты: 26.08.2021).

Толковый словарь Ожегова [Электронный ресурс]. URL: https://dic.academic.ru/contents.nsf/ogegova/ (дата обращения: 26.08.2021).

---

# СРАВНЕНИЯ С КОМПОНЕНТОМ «ЦВЕТ» КАК СРЕДСТВО ОЦЕНКИ ЧЕЛОВЕКА (НА МАТЕРИАЛЕ ТАТАРСКОГО И РУССКОГО ЯЗЫКОВ)

**Рамзия Марсовна Болгарова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
ramzija5@yandex.ru.

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
rsagadat@yandex.ru.

В данной статье в сопоставительном аспекте рассматриваются компаративные конструкции с колоративным компонентом в татарском и русском языках.

Целью данного исследования является изучение сравнительных конструкций с цветообозначениями в качестве средства описания и оценки внешнего вида человека. Материалами для исследования стали примеры из письменного корпуса татарского языка и национального корпуса русского языка. Исследуемые сравнительные конструкции используются для описания внешности людей, физического или психологического состояния человека. Данные изобразительные средства могут создавать положительный или отрицательный образ в зависимости от того, какой эталон лежит в основе сравнения.

Данные исследования могут быть использованы в преподавании русского и татарского языков, курса межкультурной коммуникации, составлении лингвокультурологических словарей и т. д.

**Ключевые слова:** татарский язык, русский язык, сравнения, колоративный компонент, внешний вид человека.